Күкшел авыл җирлеге советы

КАРАР

24 ноябрь 2022 ел №29

«Җир салымы турында» 29.11.2021елның 31
номерлы Күкшел авыл җирлеге
Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Күкшел авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 29.11.2021 елның 31 номерлы Күкшел авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «д)», «е» пунктчаларын өстәргә:

«д) Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

е) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.»

2. «Җир салымы турында» 29.11.2021 елның 31 номерлы Күкшел авыл җирлеге Советы карарының 2.1 пунктындагы «д)», «е» пунктчалары нигезләмәләренең (әлеге карар редакциясендә) гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Күкшел авыл җирлеге башкарма комитетына «Җир салымы турында» 29.11.2021 елның 31 номерлы Күкшел авыл җирлеге Советы карарының 2.1 пунктның «д)», «е» пунктчаларында (әлеге карар редакциясендә) күрсәтелгән гражданнар исемлеген формалаштырырга һәм салым органына тапшырырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Хәмидуллин Р.Р.